**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

**«26» декабрь 2024ел** **№ 173**

2025 елга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы халкы өчен торак хезмәтләре тарифларын раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта тиешле сыйфатта булмаган һәм (яисә) билгеләнгән вакыттан артыграк өзеклекләр белән гомуми мөлкәт белән идарә итү, карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәткән һәм эшләр башкарган очракта торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» карары, Татарстан Республикасы Рәисенең 2024 елның 14 декабрендәге 962 номерлы «2025 елга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индекслары турында» Указы нигезендә, ҖЧҖ «Теләче» идарәче компаниясе» нең 2024 елның 26 декабрендәге хатын карап, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Район халкы өчен торак хезмәтләре тарифларын кушымта нигезендә расларга һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертергә.
2. Муниципаль торак фондының торак урынын наемга алган өчен бер квадрат метр өчен 8 сум 80 тиен күләмендә түләү күләмен билгеләргә.
3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның «26» декабрендәге
173 номерлы карарына кушымта

2025 елга район халкы өчен торак хезмәтләренә тарифлар

| № т/б | Хезмәтнең атамасы | Үлчәү берәм леге | Күрсәтелә торган хезмәтне үлчәү берәмлеге өчен тариф (сумнарда) | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 01.01.2025 ел алып 30.06.2025 ел кадәр | 01.07.2025 ел алып 31.12.2025 ел кадәр |
| 1. | Торак фонды белән идарә итү | кв.м | 0 | 6,08 |
| 2. | Торак бинага агымдагы ремонт | кв.м | 0 | 4,28 |
| 3. | Йорт яны территориясен тоту (үләннәрне чабу һәм җыю, кардан чистарту, түбәне кардан һәм боздан чистарту) | кв.м | 0 | 5,65 |
| 4. | Йорт эчендәге сантехник канализация челтәрләрен агымдагы ремонтлау | кв.м | 0 | 3,40 |
| 5. | Йорт эчендәге электр челтәрләрен агымдагы ремонтлау | кв.м | 0 | 1,62 |
| 6. | Су белән тәэмин итүнең гомумйорт системаларын агымдагы ремонтлау | кв.м | 0 | 0,64 |
| 7. | Төтенлекләргә техник хезмәт күрсәтү | кв.м | 0 | 0,60 |
| 8. | Вентиляция каналларына техник хезмәт күрсәтү | кв.м | 0 | 0,60 |
| 9. | Фасад газүткәргечләрен ремонтлау һәм аларны карап тоту | кв.м. | 0 | 0,53 |
| 10. | Дератизация | кв.м | 0 | 0,15 |

Эшләр белән идарә итүче И.Т. Һадиев